ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.03.2021 ел Баулы шәһәре №32

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районының «Карлыгач»
ҮБСЯИУ Уставына өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2018 елның 1 июнендәге 10-06/8579 номерлы оешмаларда (учреждениеләрдә) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу чаралары турында хаты, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Карлыгач» ҮБСЯИУ Уставына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

11нче бүлектән соң түбәндәге эчтәлекле «Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу» 12нче бүлеген өстәргә:

«12. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу

12.1. Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә хезмәткәрнең шәхси кызыксынуы аның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәвенә йогынты ясарга мөмкин булган һәм шул ук вакытта Учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм Учреждение хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында каршылыклар тудырган яисә килеп чыгарга мөмкин булган, Учреждениенең мөлкәтенә һәм (яисә) эшлекле абруена зыян китерергә сәләтле булган хәл аңлашыла.

12.2. Хезмәттәге бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый торган яисә йогынты ясый ала торган Учреждение хезмәткәренең шәхси кызыксынуы дигәндә, хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, Учреждение хезмәткәре тарафыннан акча, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яисә мөлкәти

характердагы хезмәтләр рәвешендә үзе яисә өченче затлар өчен керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

12.3. Директор Учредительгә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

12.4. Учреждение хезмәткәре Учреждение директорына вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш. Учреждение директорына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган белешмәләр исемлеге, әлеге белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе Учреждение директоры тарафыннан билгеләнә.».

2. 12нче, 13нче бүлекләрне 13нче,14нче бүлекләр дип санарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары И.И. Хөснуллинга йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров